# КАРАР

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Киекле авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«18» ноябрь 2020 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 18 ноябрендә узган: «Киекле авыл җирлегенең Киекле авылы территориясендә теркәлгән һәм яшәүче, 1 гр инвалидлардан, балачактан инвалид булганнарның, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан кала, балигъ булган һәр кешедән 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Киекле авылында су җыю скважиналарын карап тоту өчен, эшләр һәм хезмәтләр башкару, товарлар сатып алу.

Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту, юл кырыйларына таш, ватылган кирпеч, грунт, вак таш, ком түшәү (сатып алу, ташу, җәю).

Киекле авылында урамнарны яктыртуны оештыру өчен эшләр һәм хезмәтләр, товарлар сатып алу.

Киекле авылының ике зиратын төзекләндерү һәм сезонлы тоту (коймаларны ремонтлау, агачларны кисү, үлән чабу).

Киекле авылында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр, товарлар сатып алу (янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру, урнаштырылган гидрантларны ремонтлау).

Киекле авылында спорт-массакүләм һәм мәдәни-массакүләм чараларны оештыру һәм үткәрү» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 731 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 459 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 359 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 100 катнашучысы тавыш бирде.

На основании изложенного, сход граждан решил:

1. Признать сход граждан в населенном пункте с. Бурметьево Бурметьевского сельского поселения Нурлатского муниципального района Республики Татарстан состоявшимся, результаты схода граждан – действительными.

2. «Киекле авыл җирлегенең Киекле авылы территориясендә теркәлгән һәм яшәүче, 1 гр инвалидлардан, балачактан инвалид булганнарның, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан кала, балигъ булган һәр кешедән 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Киекле авылында су җыю скважиналарын карап тоту өчен, эшләр һәм хезмәтләр башкару, товарлар сатып алу.

Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту, юл кырыйларына таш, ватылган кирпеч, грунт, вак таш, ком түшәү (сатып алу, ташу, җәю).

Киекле авылында урамнарны яктыртуны оештыру өчен эшләр һәм хезмәтләр, товарлар сатып алу.

Киекле авылының ике зиратын төзекләндерү һәм сезонлы тоту (коймаларны ремонтлау, агачларны кисү, үлән чабу).

Киекле авылында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр, товарлар сатып алу (янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру, урнаштырылган гидрантларны ремонтлау).

Киекле авылында спорт-массакүләм һәм мәдәни-массакүләм чараларны оештыру һәм үткәрү» мәсьәләсе буенча карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Киекле авыл җирлеге Киекле авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: Р.А.Заһертдинова

Киекле авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Р.Ә. Заһертдинова